# Олимпиада үрләренә - баскычлап

**ӘҺЛЕТДИНОВА ЛАНДЫШ ФИЛҮС КЫЗЫ**

***Актаныштагы “Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат”ның югары категорияле татар теле, әдәбияты укытучысы***

**ЯШЬ ТАЛАНТЛАРНЫҢ БЕРЕНЧЕ АВАЗЛАРЫН МӘКТӘП ЗАЛЛАРЫННАН БАШЛАП ИШЕТЕРСЕЗ.**
**ДӨНЬЯГА СИРӘК КИЛӘ ТОРГАН ТУКАЙЛАРНЫҢ ЯШЬЛЕГЕ СЕЗНЕҢ КУЛДА!**

***С.Хәким***





**БАРЫ ТИК ЭШ ДӘВАМЛЫ**


**БУЛГАНДА ГЫНА НӘТИҖӘСЕ БУЛА**

***Р.Фәхретдин***

# Укучылар алдына куелган максатлар:

- ✔ Программа материалларын бик яхшы белү;
- ✔ Өстәмә чыганаклардан мәгълүмат алу;
- ✔ Бөтен төр анализ үрнәкләрен белү;
- ✔ Вакытлы матбугат белән кызыксыну;
- ✔ Фикерләү сәләтен үстерү;
- ✔ Мөстәкыйль эшләргә өйрәнү;
- ✔ Халкыбызның үткәне, бүгенгесе турындагы материалларны өйрәнү;

# ӨЙРӘНЧЕК ОСТАЗЫН УЗДЫРСА,
# БУ – ОСТАЗНЫҢ ҖИҢҮЕ







# ЭЧТӘЛЕК

- Әдәбияттан минимум;
- Чорга характеристика;
- Әдәбиятны баскычлап кабатлау;
- Әдәбият теориясе;
- Чор әдипләре;
- Әсәрләрнең эчтәлеге, кыскача характеристика, белемнәрне тикшерү өчен сораулар, тестлар;
- Анализ үрнәкләре;
- Моны белергә кирәк;
- Олимпиада биремнәре.

# Әдәбияттан минимум:

**11 КЛАСС**

- **Г.Кутуй.** Тапшырылмаган хатлар. Сагыну. Без - сталинградчылар.
- **М.Җәлил.** Хат ташучы. Алтынчәч. Хуш, акыллым. Окоптан хат. Дуска. Кичер, илем! Кошчык. Бүреләр. Төрмәдә төш. Вәхшәт. Җырларым. Кызыл ромашка. Ана бәйрәме. Тау елгасы. Имән. *Сандугач һәм Чишмә.*
- **Ф.Кәрим.** Кыр казы. Үлем уены. Ант. Урман тын иде. Юл. Иптәш. Сөйләр сүзләр бик күп алар... Сибәли дә сибәли. Моң һәм көч. Мин - гуманист. Гөлсем. Партизан хатыны. Тимер һәм тимерче. Кыңгыраулы яшел гармун. Пионерка Гөлчәчәккә хат. Разведчик язмалары.
- **Н.Исәнбәт.** Хуҗа Насретдин. Идегәй.
- **Г.Бәширов.** Туган ягым - яшел бишек. Намус…

# Әдәбиятның чорларга бүленеше

- **БОРЫНГЫ ӘДӘБИЯТ**

**Гомумтөрки әдәбият (V—XIII гасырның I чирегe)**

- **УРТА ГАСЫРЛАР ӘДӘБИЯТЫ**
- **Болгар чоры әдәбияты (IX—XIII гасырның I чиреге)**
- **Алтын Урда чоры әдәбияты (XIII гасыр уртасы — XV гасыр уртасы)**
- **Казан ханлыгы чоры әдәбияты (XV гасыр уртасы — XVI гасыр уртасы)**
- **Торгынлык чоры әдәбияты (XVI гасыр уртасы — XIX гасыр уртасы)**

- **ЯҢА ЗАМАН ӘДӘБИЯТЫ**
- Милли Яңарыш чоры әдәбияты (XIX гасыр уртасы — 1917)
- Мәгърифәтчелек әдәбияты формалашу (XIX гасыр уртасы — 1905)
- XX гасыр башы әдәбияты (1905—1917)

# 30 нчы еллар әдәбиятына гомуми күзәтү

- **Чор үзенчәлекләре**

**1.** Дингә каршы көрәш дәүләт күләмендә тормышка ашырыла.
**2.** 30 нчы еллар уртасында, илдә “шәхес культы”на бәйле репрессияләр башлана, меңнәрләгән кешеләр бер гаепсезгә үтерелә, төрмәләргә ябыла, лагерьларга җибәрелә. 60 миллион гаепсез кеше юк ителә.
**3.** Колхозлаштыру киң җәелдерелә. 20 нче еллар ахыры – 30 нчы еллар башында мәҗбүри рәвештә күмәк хуҗалыклар төзелә, чын җир хуҗаларының байтагы “кулак” исеме белән Себер якларына сөрелә.
**4.** 1929 нчы елда гарәп графикасы – латинга, ә 1939 – 1940 нчы еларда кириллицага алыштырыла. Бу халыкның зур катламын үзенең бай язма әдәбиятыннан, тарихи ядкярләреннән читләштерүгә китерә.
**5.** Әдәбиятта “социалистик реализм”, “совет әдәбияты”, “совет язучысы” төшенчәләренә нигез салына.
**6.** Әдәбиятта үсеш-үзгәрешләр, эстетик эзләнүләр кими, “актуаль” темага язылган, бер-берсенә бик нык ошаган, ләкин укучыларда кызыксыну уятмый торган әсәрләр күпләп языла.
7. Хакимлек иткән идеологиядәшн читләшкән яисә хакимиятнең төрле якларын тәнкыйтьләгән әсәрләргә “кара пәрдә” ябыла. (Ф.Әмирхан “Шәфигулла агай”, Г.Ибраһимов “Адәмнәр”, Г.Рәхим “Идел”, Х.Туфан “Ант” һ.б.)
**8.** Татар әдәбияты 30 нчы елларда да сакланып, яшәп кала, үсеш-үзгәрешен туктатмый, чөнки:
- татар әдәбиятының ерак гасырлардан килгән олы реалистик традицияләре һәм XX гасыр башында күтәрелешенең “алтын чоры”н кичерүе бик күп буын язучылар өчен зур таяныч, терәк була;
- 1917 нче ел алдыннан татар әдәбиятында Г.Исхакый, Г.Ибраһимов, Дәрдемәнд, Ф.Әмирхан, Ш.Камал, Г.Камал кебек югары абруйлы каләм осталарының хезмәт итүе, күбесенең 20-30 нчы елларда да иҗат эшчәнлегеннән аерылмавы татар сүз сәнгатенә билгеле бер сыйфат дәрәҗәсендә калырга мөмкинлек бирә;
- Бу чорда әле татар әдәбияты яшь көчләрне төрле төбәкләрдә үзенә тартып тора (Оренбург – М.Җәлил, Саратов – Г.Кутуй, Тамбов – Һ.Такташ, Башкортстан – М.Әмир, Ф.Кәрим һ.б.)

**Поэзиядә (*прозада…, драматургиядә…*) күтәрелгән темалар:**
1) авыл һәм шәһәрдәге үзгәрешләр;
2) табигать;
3) тарих;
4) инкыйлаб;
5) шәхес язмышы турында уйланулар…


**Уңышлы әсәрләр: …**
**Әдәбиятта өстенлек иткән жанр төрләре: …**

**Тагын укыгыз:**


Галимуллин Ф. Әле без туганчы... / Ф.Галимуллин. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2001.
Галиуллин Т. Утызынчы еллар татар шигърияте / Т.Галиуллин // Шигърият баскычлары. – Казан: Мәгариф, 2002. – Б.91-125.
Голубков М.М. Русская литература XX в.: После раскола: Уч. пособие для вузов. – М.: Аспект Пресс, 2001.
Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. Т.4. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1989

# VI класс

| Әсәрнең исеме | Авторы | Жанры | Язылу вакыты | Төп геройлар | Ярдәмче геройлар | Кем исеменнән хикәяләнә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Беренче театр | Галиәсгар Камал | Комедия | 19...? | Хәмзә бай, Биби | Гафифә -Вәли, -Хәбибрахман - Факиһә | Автор |



# Әдәбият теориясе




КЕШЕ ОБРАЗЛАРЫ

1. төп
2. ярдәмче
3. эпизодик
4. аталучы

ИҖАТ ЮНӘЛЕШЛӘРЕ

1. реализм
2. романтизм
3. модернизм

ӘДӘБИ АЛЫМНАР

1. портрет
2. пейзаж
3. әйберләр дөньясы
4. психологизм
5. шартлылык
6. хронотоп

ТЕМА:

1. Мәңгелек
2. Милли
3. Тарихи
4. Персональ

# Мирсәй Әмир
# “Миңлекамал” драмасы (1944)

***Кыскача сюжеты***

“Яшел алан” колхозына председатель билгеләргә кирәк. Моның өчен райком секретаре Гыйльманов шул колхозда эшләүчеләрнең шәхси делоларын тикшерә, туры килерлек кандидатура эзли. Анкеталарны актарып чыккач, Миңлекамал Сәфәргалиевага туктала. Аны үз янына чакыртырга куша, ләкин, ни гаҗәп, Миңлекамал үзе үк “Яшел алан” колхозына председатель итеп тәкъдим итүләрен сорап килә. Ул председатель итеп билгеләнә.

Беренче көннән үк Миңлекамал җиң сызганып эшкә керешә. Аның үзен үзе кызганмыйча, алны-ялны белмичә эшләве чыннан да “Җенлекамал” булуын дәлилли. Ләкин колхозда эшләр шома гына бармый. Чәчү вакыты җиткәч, орлыкларның чәчәргә яраксыз булуы ачыклана. Җаваплылыкны үз өстенә алып, Миңлекамал чәчәргә куша һәм ялгышмый. Миңлекамалның эшенә аяк чалучылар да табыла. Хәлим һәм Мәймүнә Миңлекамалның һәр адымын тикшереп торалар. Берәр кыек адымы, ялгышлыгы булса, шунда ук райкомга җиткерә торала.

Миңлекамалның председатель булуы бөтен авылны эшкә дәртләндерә: яшен дә, картын да. Барысы да тырышып хезмәт куялар, колхозларын алдынгылар рәтенә чыгарырга тырышалар.

Бервакыт колхозга, Миңлекамалны тикшерергә дип, Казаннан кешеләр килеп төшә. Ахыр чиктә барысы да ачыклана, дөреслек өскә чыга. Мәймүнә белән Хәлимнең кырын эшләре өскә калка: Миңлекамалны тикшерергә дип килгән кеше аларны тикшерә. Председательгә дип казылган чокырга үзләре төшәләр.

**Жанры**: драма.

**Сюжет-комппозициясе:** Биш пәрдәдә, сигез картинада.

**Төенләнеш**: Гыйльмановның “Яшел алан” колхозына председатель сайлавы, Миңлекамалга тукталуы, Миңлекамалның шул ук үтенеч белән үзе килүе.
**Вакыйгалар үстерелеше**: Миңлекамалның председатель итеп билгеләнүе, авыл халкының колхозны аякка бастыру өчен җиң сызганып эшләве.
**Кульминацион нокта**: Миңлекамалны тикшерергә Казаннан кеше килү.
**Чишелеш:** барысы да ачыклану, гаепле кешеләрне фаш итү.

**Төп образлар**: Миңлекамал, Маһинур, Гайни, Әмми, Нәфига, Әхмәдулла карт, Хәлим, Мәймүнә.
**Ярдәмче образлар**: Гыйльсанов, Хаҗи, Хуҗа, Венера, Талип, Ходайбирдин.

**Темасы**: Бөек Ватан сугышы көннәрендә авыл хезмәт ияләренең фидакарь хезмәте, сугыш китергән авырлыклар, яхшылыкның начарлыкны җиңүе.

**Идеясе**: дөреслек һәрвакыт өскә чыгачак, үз көчеңә ышанып, тырышып эшләгәндә генә уңышка ирешеп булачак.

# Гариф Ахуновның “Хәзинә” романы геройлары

**Йөзлекәй карчык** — 11бала ------------Гобәйдулла (Көбәш карт)

Шәвәли Мәгыйшә | 5 баласы үлгән | 3 кызы күрше-тирә авылларда кияүдә | Әбүзәр (сугышта үлгән) Сәлимә | Баязит( Үзбәктә) Таһирә

Шәвәли – Мәгыйшә (4 баласы)

Фәйрүзә | Арслангали | Мәрзия | Габделхәй

Булат Дияров (Тансык-уллары)

(Мөнәвәрә классташлар, яратышалар)

Кәрим---------Мөнәвәрә Тимбиковлар
(мастер)
Миләүшә----------Әнвәр
(балалары)

Лотфулла------------Тәүфика Дияровлар
Сәлим Илдар Разия Рәйсә Кәрәм
(балалары)

Кожанов--------трест начальнигы


Зозуля----------контора директоры

# Әдәби әсәр анализлаганда файдалану өчен терәк схема үрнәкләре


**Чәчмә әсәр анализлау планы**

- 1. Әсәрнең язылу вакыты, тарихы (билгеле һәм кирәк булса).
- 2. Төп әдәби образлар системасы. Аларны сыйфатлау.
- 3. Сюжет бирелеше. Конфликт.
- 4. Әсәрнең тема, проблема, идеясе.
- 5. Сурәтләнгән дөнья ( пейзаж, портрет, әйләнә-тирә дөньяны тасвирлау).
- 6. Әсәрнең композициясе.
- 7. Әсәрнең теле (автор сөйләме, хикәяләү, сурәтләү, персонажлар сөйләме, тел-сурәтләү үзенчәлекләре).
- 8. Жанры.
- 9. Әсәрнең язучы иҗатында тоткан урыны.
- 10. Татар әдәбиятына алып килгән яңалыгы.

# АЛЬТЕРНАТИВ ДӘРЕСЛЕКЛӘР:









# Интернет ресурслар:




| | |
|---|---|
| Габдулла Тукай | http://gabdullatukay.ru |
| ТР Электрон газетасы | http://www.intertat.ru |
| Әдипләр | http://adiplar.narod.ru |
| Татар электрон китапханәсе | http://kitap.net.ru |
| Татар телен өйрәнү өчен | http://www.languages-study.com/tatar-links.html |
| Татарлар | http://www.tatarlar.ru |
| ТР Милли китапханәсе | http://kitaphane.tatar.ru |
| Татарча сайт | http://tatarca-text.narod.ru |

# ЭЛЕКТРОН ДӘРЕСЛЕКЛӘР



**Тырышсын, сәләтле булыр!**

**Баш ватсын – башлы булыр!**

**Көч түксен – көчле булыр!**

**ЙӨК БАЛА КҮТӘРМӘСЛЕК КЕНӘ**

**БУЛМАСЫН!**

# ИГЪТИБАРЫГЫЗ ӨЧЕН РӘХМӘТ